«Адымнар-Түбән Кама» күптелле мәгариф комплексы

# АдымнарTimes

Полилингвальный образовательный комплекс
«Адымнар-Нижнекамск»


№ 2, май 2023 г.

adymnartubenkama
adymnartubenkama




«Гыйлем-FEST»: проектлар илендә, 4-5 нче бит



Милана Стар кунакта

## АНОНС

4 **С заботой об окружающей среде:** самые яркие проекты «Наука-FEST»

6 **«Персона». Эмиль Сайфуллин:** из «художника» - в учителя

6 **«Блиц-интервью»:** 3 вопроса президенту школы

8 **«Парламентский урок»:** в гостях заместитель мэра Марина Камелина

**ТАТАРЧА ЯЗАБЫЗ:**

2 **Хөрмәтле кунакларыбыз:** Марат Готыф улы Әхмәтовның мәктәпкә килүе

3 **Туган телләр семинары:** иң мөһиме генә

5 **Фән фестивале:** балалар тормышка ашыра торган проектлар

6 **Эмиль Сәйфуллин: аның үрнәге кем?**

**ENGLISH**

6 **Emil Sayfullin's dreams**

7 **In the world of English**




«Адымнар»ның кыйммәтләре 8 стр.

## Слово редактора



### УВАЖАЕМЫЕ ЧИТАТЕЛИ!

**Вы держите в руках второй номер газеты «Адымнар TIMES».**

Мы смело можем сказать: наша школа успешно отработала первый год! Это время было для нас непростым, но в то же время интересным и насыщенным яркими событиями.

Об этом вы можете судить лично, прочитав материалы, подготовленные нашими педагогами и детьми.

Мы очень старались! Надеемся, что вам понравится очередной выпуск, который мы готовили с любовью.

Рәхим итеп укыгыз!

***С уважением, редактор газеты Ксения ПУШКАРЁВА***

## Рәсми

# Безгә бүген бердәм булырга кирәк



**Безнең комплекста «Милли мәгариф – тел, мәдәният, милләтебез киләчәге» темасына түгәрәк өстәл үтте..**

**«Милли мәгариф – тел, мәдәният, милләтебез киләчәге» темасына багышланган түгәрәк өстәлне Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы Рамил Хәмзә улы Муллин ачты. Ул кунакларны сәламләде. Максатларны билгеләде.**

Сәламләү сүзеннән соң, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы Айдар Хәкимҗан улы Гарифуллин чыгыш ясады. «Мәктәпләрдә милли төркемнәр санын арттыру максатын күздә тотмыйбыз, төп бурыч – сыйфат өстендә эшләү. Һәм бу эшкә бөтенебез дә зур өметләр белән карыйбыз» – ди Айдар Хәкимҗан улы.

Җавап сүзен әйтү өчен сүз Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты этикасы кагыйдәләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе рәисе Әхмәтов Марат Готыф улына бирелде: «Үлчәүгә салып булмый, тиз генә нәтиҗәгә чыгып булмый торган яшәештә яшибез. Без 30-40 ел эчендә бик нык үзгәргәнбез. Мин инде өлкән буынга керәм. Безнең кыйммәтләр икенче төрле иде. Безнең яшәү рәвешебез үк сәламәт түгел. Без милләтебезнең гомерен озынайтырга тырышырга тиешбез. Милли мәгариф мәсьәләсенә килгәндә без гаепсездән гаеп эзлибез. Милли мәгарифкә бик сак, матурлыкны күрсәтеп килергә кирәк. Ватып-сындыру дөрес түгел. Рәисебез бөтен проектларга уңай карый. Түбән Кама җитәкчелегендә миллилек көчле. Мондый җитәкчеләр булганда бу пробеламаларны җиңәрбез дип уйлыйм. Сезнең һәм безнең алдыбызда хәйран эш нәтиҗәсе тора. Үземә бурычлар билгеләп, җиң сызганып эшләргә кирәк дигән теләктә калам».

Түгәрәк өстәлнең ачык микрофон өлешендә сорау бирү мөмкинлекләре дә булды. Анда милләткә, төрле проектларга, татар теле дәреслекләренә, хисап алуга багышланган сораулар яңгырады. Марат Готыф улы Әхмәтов ул сорауларга бик аңлаешлы итеп ачыклык кертте.

Түгәрәк өстәлне Рамил Хәмзә улы Муллин йомгаклады: «Һәр халык үзенең телен, культурасын, гореф-гадәтләрен белергә тиеш. Безнең төп максатыбыз – дөрес орлыклар салуда. Безгә бүген нәрсә булдыра алабыз, шуны эшләргә кирәк. Үз-үзебезне, балаларыбызны дөрес тәрбияләргә тиешбез. Тәрбияне үзебездән, үзебезнең оешмалардан башларга кирәк. Безгә бүген бердәм булырга, кул төшермәскә кирәк. Шулай без алга бара алабыз».

***Зөлфия ЯЛАЛОВА, туган тел һәм әдәбият укытучысы***

# Татар артистлары кунакта



*«Адымнар-Түбән Кама» күптелле белем бирү комлексына татар эстрадасының танылган артистлары – Гүзәлем һәм Салават Миңнехановлар килде.*




*Танылган кунакларга укучылар үзләренең кызыксындырган сорауларын бирделәр, әңгәмә бик күңелле үтте.*

Семинар

# Туган телләр укытуның актуаль проблемалары: дөньядагы иң яхшы тәҗрибәләр

**28 нче февраль көнне мәктәбебездә «Туган телләрне укытуның актуаль проблемалары: дөньядагы иң яхшы тәҗрибәләр» дигән темага төбәкара фәнни-методик семинар узды.**

Семинарның максаты: белем бирү дәрәҗәләре арасындагы эзлеклелекне исәпкә алып, туган телләрне өйрәтү процессын оештыру буенча дөньякүләм һәм Россия тәҗрибәсе белән танышу, киләчәккә эш перспективаларын билгеләү; туган телләр үсешен укыту-методик тәэмин итүнең уңай тәҗрибәләрен тарату; туган телләрне саклап калуга һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларның актуальлеген тикшерү, Татарстан Республикасы халыкларының рухи мирасына кыйммәтле мөнәсәбәт формалаштыру.

Чарада Татарстан Республикасы Тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен торгызу республика фонды директоры Зөлфия Хафиз кызы Сөнгәтуллина, Түбән Кама муниципаль районы Мәгариф идарәсе башлыгы Айдар Хәкимҗан улы Гарифуллин; Казан, Чаллы, Актаныш, Әлмәт һәм Алабуга шәһәрләреннән укытучылар, шулай ук Башкортостан Республикасының Нефтекамск күп профильле интернат-мәктәбенең һәм Түбән Кама уку йортларының делегациясе булды.

*«Бүген туган телне саклау һәм өйрәнү проблемасы бик актуаль. Татар телен мәктәптә генә өйрәнү җитми, белем бирүдән тыш тәрбияләү дә мөһим. Шуны аңларга кирәк: хәзерге буынның туган теленә кызыксынуын арттыру өчен яңа укыту методикалары кирәк», – диде Зөлфия Сөнгәтуллина.*



Семинарның төп темалары - туган телгә, әдәбиятка өйрәтүнең нәтиҗәле ысуллары һәм гомуми белем бирү оешмасында туган телгә өйрәтү проблемасы һәм технологияләре. Шулай ук, туган телләрне саклау һәм үстерү буенча иң яхшы тәҗрибәләрне презентацияләү иде.

«Адымнар-Түбән Кама» МББУ укытучылары татар һәм инглиз телләрендә интеграль дәрес, математика, татар теле, тарих һәм әйләнә-тирә дөнья дәресләрен татар телендә күрсәттеләр. Шулай ук анимация, блогерлык, театр, журналистика, шахмат, чуваш һәм рус теле буенча мастер-класслар тәкъдим ителде.



Пленар утырышта семинарда катнашучылар сорауларга җавап бирделәр, дискуссияләрдә катнаштылар, үз тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.

Барлык катнашучылар да сертификат алдылар. Кунаклар һәм коллективыбыз өчен дә әлеге чара зур бәйрәм төсен алды. Семинар бик кызыклы һәм эчтәлекле үтте.

***Энҗе Зайдуллина, туган тел һәм әдәбият укытучысы***

Төрекчә сөйләшәбез

# «Турки в турке»: нәрсә турында сөйлиләр?

**«Адымнар-Түбән Кама» мәктәбендә төрле милләт вәкилләре белән очрашулар үткәрелә. «Турки в турке» түгәрәге әгъзалары өчен Төркиядән килгән мөсафир белән әңгәмә оештырылды. Ул да булса Мехмет Унверен. Шәхесебез бердәнбер һәм кабатланмас Истанбул шәһәреннән күченеп килгән.**

Укучыларыбызның хис-кичерешләре белән танышып алыйк. Бу очрашу аларга ничек тәэсир иткән?

**Камилә Кадырова (6а):**

– Миңа дәрес бик ошады. Кунак белән очрашуыбыз җиңел һәм шул ук вакытта дулкынландыргыч үтте. Безнең кунагыбыз рус телен бик яхшы белә икән. Кызлар белән аннан рус телендә сөйләшергә сорагач, ул акцентсыз берничә сүз әйтте, бу бик гаҗәп! Очрашудан соң, минем төрек телен тирәнтен өйрәнергә теләгем туды!

**Аделина Гайнетдинова (7а):**

– Сишәмбе көнне безнең төрек теле дәресе узды. Әлеге дәресне укытучыбыз түгел, ә Төркиядә туып үскән кунак алып барды. Без аңа тормыш юлына һәм Төркиядә яшәвенә кагылышлы сораулар бирдек. Чит ил кешесе белән аралашу бик кызык иде, чөнки без башка милләт кешеләрен сирәк очрата алабыз. Бу дәрес ярдәмендә без төрек телендә яхшырак аралашырга өйрәндек һәм дикъкатебезне җәлеп иткән яңалыклар белдек.

**Арина Семёнова (7б):**

– Күптән түгел мәктәбебездә Төркиядән килгән кунак белән очрашуыбыз узды. Дәрес бик күңелле һәм мавыктыргыч булды. Мондый очрашулар кирәкле тәҗрибә тупларга ярдәм итә һәм төрек телен өйрәнүгә этәргеч булып тора. Шәхсән мин яңа сүзләр өйрәндем, төрек халкының үзенчәлекле гореф-гадәтләре белән таныштым. Дәрестә җылы атмосфера хөкем сөрде. Мондый дәресләр күбрәк булса иде! Кунагыбызга чиксез рәхмәтемне белдерәсем килә!

***Эльвина Унверен, татар һәм төрек теле укытучысы***

# ДОБРО СЕЯТЬ – ДОБРО ПОЖИНАТЬ

**Как сохранить планету для будущих поколений? Это, пожалуй, одна из вечных проблем человечества.**

**Ученикам нашей школы было предложено порассуждать на эту тему, представив свои идеи в проектах. Что и говорить, получилось интересно и зрелищно, а выступления дали повод для проведения грандиозного события – фестиваля науки «Наука-FEST».**

**На страницах газеты «Адымнар Times» мы расскажем о нескольких проектах.**

*«Наука-FEST»*

**«Выращивание микрозелени для школьной столовой», 6Б класс (руководитель М.Т.Гилазтдинова).**



– Как известно, с наступлением весны организм человека начинает испытывать нехватку витаминов, – рассказывают дети. – Очень много витаминов в растениях, например, в свежей зелени. Но зимой и ранней весной свежая зелень стоит дорого. Поэтому мы решили разработать проект по выращиванию микрозелени прямо у нас в школе – в кабинете биологии. Выращенную зелень будем предлагать в школьную столовую.

Нам повезло, ведь в школьной лаборатории биологии у нас есть гидропонная установка «Домашний сад» для выращивания растений в помещении. Сверху установка имеет освещение для постоянного осуществления фотосинтеза, внизу есть контейнер, куда наливается вода и позже всасывается в горшочки. Собрав это оборудование, мы всей командой с нашим руководителем посадили семена шнитт-лука, брокколи, гороховых усиков, кольраби. Позже мы решили увеличить количество выращиваемой зелени. Посадили её в контейнеры с землей, то есть на этот раз обошлись традиционным способом посадки.

Планируем предлагать наш урожай не только школьной столовой, но также в дальнейшем продавать на ярмарках, – заключили юные биологи.

**«Съедобная экопосуда», 7А класс (руководитель Р.Г. Абдиева)**

– В самый разгар весны люди выезжают на природу и устраивают пикники. Покупают одноразовую пластиковую посуду, оставляют её, тем самым загрязняя окружающую среду, – объясняют ребята. – Именно поэтому мы хотим представить нашу линию съедобной экопосуды, которую можно употреблять в пищу и легко приготовить в домашних условиях. Например, желейный экостаканчик. По вкусу он похож на мармелад. Или же сырная тарелка, которая станет хорошей заменой обычной. Экопосуду можно использовать на разных праздниках, она вкусная и по-




лезная. Вообще съедобная посуда в России редкость, и мы очень надеемся, что большинство из вас начнёт пользоваться такой посудой. Будем же друзьями природы! – призывают ребята.

**«Мобильные отели для пчёл», 1Г класс (руководитель Г.И. Ахмадиева).**

– Из 100 видов сельскохозяйственных культур, которые обеспечивают 90% продовольствия на планете, более 70% опыляется пчёлами, – объясняет актуальность выбранной темы Гульназ Ильфатовна. – Так, с пчелами связано производство трети продовольствия в мире. Однако использование химикатов и резкие изменения в климате могут привести к вымиранию этих насекомых. Именно поэтому мы с ребятами разработали данный проект. Что же нужно для его реализации?



Во-первых, рассказать об этой проблеме. Во-вторых, не использовать химикаты, а в-третьих, создавать для пчёл новые места обитания – строить отели. Они будут представлять собой домики из натурального дерева с отверстиями под углом, чтобы не попадали осадки. Схема конструкции несложная: небольшой размер, удобное и надежное крепление в доступных местах. Вот и всё! Давайте создавать условия для жизни пчёл вместе!

**Обратная связь**

**Гульшат Ахъярова, заместитель директора по ВР полилингвальной многопрофильной школы-интернат «Белем» (г.Нефтекамск, Республика Башкирия):**

– Насыщенность и содержание мероприятия раскрыли все вопросы полилингвальности и задали темп для дальнейшей работы. Вы делом доказали, насколько много вкладываете в детей, ведь подготовить и отработать на высоком уровне – это колоссальный труд! И в этом, без сомнения, заслуга каждого педагога. Смело можно сказать, что вы вырастили смелых и конкурентноспособных детей!

Педагогический коллектив идеально подобран именно под вашу школу, он компетентен и профессионален. Желаем вам неиссякаемой энергии и вдохновения!

## «СИБУР» в гостях



*Ученики 1а класса демонстрируют гостям из «СИБУР» проект «Вторичное использование полиэтиленового пакета». Своими руками ребята смастерили кукол, цветы, картину и другие предметы.*

## Милана Стар




*В «Адымнар» приезжала известная певица и блогер Милана Стар. Вместе с ребятами она села за парту и приняла участие в экоуроке «Вторая жизнь пластика», подготовленным компанией «СИБУР».*

Фән фестивале

# Агач утырткан – ага булган

Экология проблемасы үзенең үткенлеге белән бүген бөтен кешелек алдына килеп басты. Чөнки киләчәк буыннар язмышын фән-техника казанышлары түгел, ә җир-суларның экологик торышы хәл итәчәк. Экологик аңлылык, фикерләү дәрәҗәсе, мәдәнилек – болар килеп туган хәлдән чыгуның бердәнбер юлы булып тора.

Мәктәбебезнең 5б һәм 5в сыйныф укучылары Аделина Моисеева һәм Самат Гыйләҗетдинов «Ылыслы агачларның кеше сәламәтлеге өчен файдасы» дип исемләнгән темага үзләренең проектларын тәкъдим иттеләр.




Тема актуаль, чөнки хәзер яңа микрорайоннар күбәя һәм яшелләндерү мәсьәләсе бик кискен тора. Кешеләр азрак авырсын өчен саф һава зур роль уйный. Ылыслы агачларны утырту микрорайонның тышкы күренешен яхшыртып кына калмый, ә кешенең сәламәтлеге өчен дә зур файда китерә. Эшебезнең максаты - ылыслы агачларның кеше сәламәтлегенә уңай йогынты ясавын исбатлау иде. Эш барышында укучылар 31 нче микрорайонда яшәүчеләрне анкеталаштырдылар, табиб белән әңгәмә үткәрделәр һәм кызыксындырган сорауларга җавап алдылар. Шулай ук 5-6 сыйныф укучылары «Агач – безнең яшел дустыбыз» дигән темага иншалар яздылар һәм өстәмә әдәбият белән танышканнан соң, чыршылар фитонцидларга – биологик актив матдәләргә бай һәм алар авыру тудыра торган микроорганизмнарны юк итү үзлегенә ия булуын белделәр. Чыннан да, шәһәрне чистартуда һәм савыктыруда агачларның роле бәяләп бетергесез. Алар тузанны, углекислый газны йотып кына калмый, ә кислород эшләп чыгара, санитар-саклау, су саклау һәм тавыштан саклау функцияләрен дә башкара, шәһәрнең микроклиматын һәм йөзен формалаштыра.

Безнең микрорайон яшь. Биредә яшелләндерүгә, ә нәкъ менә ылыслы агачлар утыртуга зур игътибар кирәк. Без үз йортларыбыз янында ылыслы агачлар утырттык, шул рәвешле табигатебезне яшелләндерүгә үз өлешебезне керттек. Шулай ук Адымнар мәктәбенең әтиәниләре белән «Чыршы утырт» акциясен үткәрүне планлаштырабыз. «Агач утырткан – ага булган». Бу сүзләрдә нинди тирән мәгънә ята. Дөрестән дә, бер генә агач утыртсаң да, табигатькә, бөтен әйләнә-тирәлеккә күпме файда китерәсең. Агачкуаклар тирә-як мохитебезне матурлаучы, саклаучы булып торалар. Юкка гына урманны галәмебезнең үпкәсе димиләр. Һәркайсыбызның сәламәтлеге дә яшеллек белән нык бәйләнгән. Табигатьнең матурлыгы һәм байлыгы безнең кулда. Әйдәгез, барыбыз да табигать сагына басыйк!

***Энҗе ЗАЙДУЛЛИНА,***
***туган тел һәм әдәбият укытучысы***

# «Балачак.FM» балалар радиосы

**«Фән-Fest» фестивалендә 6 нчы «Г» һәм «А» сыйныф укучылары «Балачак.FM» дип аталган интернет-радио проектын тәкъдим иттеләр. «Балачак.fm» интернет-радиосының максаты нидән гыйбарәт икән соң?! Без укучылардан сорарга булдык.**




**Ясминә Зәрипова:** «Балачак.FM» – балалар һәм яшүсмерләр өчен белем бирү һәм мәдәни-агарту интернет-радиосы. Бөтендөнья пәрәвезе киңлекләрендә татар телендә эшли».

**Камилә Кадырова:** «Балалар һәм яшүсмерләр өчен радио эфирыннан тапшырыла торган махсус файдалы контент аз булу сәбәпле, радионы оештыручылар әлеге мәсьәләдә ныклы аналитика ясады һәм шәһәрдә яшь буын өчен әлеге радионың кирәк булуын билгеләде».

**Илина Фәзуллина:** «Радио – татар телендә эшли. «Балачак.FM»да һөнәр сайларга ярдәм итә, уңышка омтылу хисе уята, белемнәрне арттыра. Интернет-радиода дөньяны күзаллауны киңәйтә торган мәгълүмати тапшырулар әзерләнә. Нинди дер өлкәдә уңышка ирешкән һәр яшүсмер үз талантын күрсәтә, үз таланты турында сөйли ала. «Балачак.FM» – яшь буынга үзләрен алып баручы буларак сынарга, әлеге өлкәгә беренче адымнарын атларга мөмкинлек бирүче мәйданчык».

«Балачак.FM»да һәр укучының эше билгеле: кемдер исә мультфильмнарны татар телендә тавышландыра, кемдер татарча сүзләр, ә кемдер исә тәмле итеп ашарга пешерергә өйрәтә. Тагын «Сәламәт тәндә-сәламәт акыл», «Әдәби дәрья» һәм «Татарча җырлар» кебек рубрикалар да бар. Укучылар Контактта» челтәрендә үзләренең төркемнәрен дә булдырганнар. Без аларга зурдан-зур уңышлар телибез!

***Зөлфия ЯЛАЛОВА,***
***туган тел һәм әдәбият укытучысы***

Шәхес

# ЭМИЛЬ САЙФУЛЛИН: «С МОТИВАЦИЕЙ МОЖНО ВЫУЧИТЬ ЛЮБОЙ ЯЗЫК»

**Сегодня гостем редакции «Адымнар Times» стал учитель английского языка и технологии Эмиль Римович Сайфуллин. Несмотря на то, что он является молодым педагогом, можно смело сказать, что он завоевал авторитет у детей, коллег и руководства. Кстати, Эмиль Сайфуллин представлял нашу школу на престижном муниципальном конкурсе «Учитель года - 2023» и стал лауреатом в номинации «Открытие года».**

**Алия: Эмиль Римович, расскажите, пожалуйста, как Вы выбрали профессию учителя?**

**Эмиль Сайфуллин** *(далее – Э.Р.)*: Я учился в лицее-интернате №24. У меня был молодой классный руководитель Рашит Накипович Хатбуллин – он только-только окончил университет, и мы стали его первым классом. Когда позже передо мной встал выбор профессии, он, имея в виду педагогическое направление, сказал мне: «Эмиль, у тебя всё получится!» Так я решил поступить в пединститут по специальности «Учитель английского языка».

**Victoria: Who did you want to be as a child?**

**Э.:** Good question! *(laughs)* You know, I wanted to become an artist, but I've never been good at painting.

**Сәмирә: Балачагыгызда кемгә карап соклана идегез? Кемне үрнәк буларак күрә идегез?**

**Э.Р.:** Лицеебызның мөдире – Алмаз Госман улы Шәкирҗанов, мөгаен. Ул камил дәрәҗәдә татар, инглиз һәм төрек телләрендә аралаша иде. Тышкы кыяфәте дә һәрвакыттагыча җитди һәм пөхтә иде.





**Элина: Димәк, сез төрек телен лицейда өйрәндегез?**

**Э.Р.:** Әйе, әлбәттә. Безнең лицеебызда төрек телен төрекләр үзләре укыта иде. Соңыннан исә, алар киткәннән соң, башка укытучылар әлеге эшне дәвам итте.

**Аиша: В чём сложность изучения иностранных языков?**

**Э.Р.:** Препятствием я бы назвал только лень. Если есть мотивация и желание, можно выучить любой язык.

**Эльвина: Вы участвовали в конкурсе «Учитель года – 2023»: что помогло вам в этом?**

**Э.Р.:** Конечно, это команда! Я знал, что могу рассчитывать на помощь коллег, поэтому было не так страшно *(улыбается)*. Одному к такому серьезному конкурсу было бы нереально подготовиться.

**Әминә: Сезнең фикерегезчә, яхшы укучы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

**Э.Р.:** Бераз уйларга вакыт бирегез... Минемчә, тәртипле, дәрестә актив катнаша торган һәм һәрвакыт белемгә омтылган шәхес кенә яхшы укучы исеменә лаек.

**Larina: Continue the phrase: «My dream is …»**

**Э:** … to travel around as many countries as possible! I want to see not only the sights, but the way of life of people as well. The top 3 countries I want to visit are bright Brazil, picturesque Switzerland and Japan, the land of the rising sun.

Блиц-интервью

# 3 вопроса президенту «Адымнар»

**– Привет, Рустам! Меня зовут Виктория Голякова. Я корреспондент газеты «Адымнар Times». Хочу задать тебе пару вопросов. Расскажи, пожалуйста, как ты мечтаешь изменить «Адымнар»?**

– Здравствуй, Виктория! Мне очень хочется, чтобы атмосфера в нашей школе стала образцом дружелюбия и взаимопонимания. Это цель №1.

**– Что нужно сделать для этого?**

– Предлагаю несколько преобразований. Например, сформировать школьное самоуправление, организовать шефскую помощь неуспевающим ребятам, создать почтовый ящик президента для вопросов и предложений. И, конечно, всеми долгожданная «джинсовая пятница», когда раз в месяц можно будет прийти в школу в джинсах. Считаю, что это будет новый уровень взаимоотношений между нами, учениками, и учителями.

**– Бу тәкъдимнәр бик кызык! Үзең турында бераз сөйләп китә алмассыңмы?**

– Мин сәламәт яшәү рәвешен алып барам, халык биюе түгәрәгенә йөрим, информацион технологияләр белән кызыксынам.

**– Гәҗитебезнең редакциясе сиңа уңышлар тели, Рөстәм! Сайлау алды слоганыңда әйткәнеңчә: «Көчле президент – көчле мәктәп!»**



– Рәхмәт! Тырышырмын!

***Беседовала Виктория Голякова***

From the world of English

# STEP TO SUCCESS

**The key focus of the educational process of the multilingual educational complex «Adymnar-Nizhnekamsk» is the formation of a multilingual multicultural personality. Starting from primary school, students are taught in three languages: Russian, Tatar, and English. At different levels of school education, each of the three languages acts as the language of study and the language of instruction.**

The English language starts being taught from the 1st grade. Starting early in the children's education of the foreign language generates a strong interest in the further study of English, thus becoming more impactful. A child gets the opportunity to learn the language for his personal growth and adds higher career choices in the future. This in turn helps the children further develop their emotions, will, imagination, memory and thinking skills. Studying the language in lessons, as well as using it in extracurricular activities, helps the child to learn to use his/her interpersonal communication abilities, self-control skills, along with acquiring the ability to solve tasks collectively, and the practical use in the foreign language.

In the middle of March, our English teachers organized



«The English Language Week». The main aim of this event was to improve the speech competence of students in all different types of speech activities, the practical application of the acquired skills to solve creative problems, the formation of students' creative activity and creative thinking. The ten-day English festival has the capacity of being a great educational, educative and development value. It not only deepens and expands the knowledge of a foreign language, but also promotes the expansion of the cultural outlook of the students, it develops aesthetic taste and as a consequence, raises the motivation to study other languages and cultures of countries other than their own. When organizing and conducting English week, our dedicated teachers are guided by the interests of students, taking into account their age and psychological characteristics.




The English Week began with the «ABCs» exhibition made by the 1st grade students. Our little stars took an original approach to the design of the English alphabet and it showed their creative imagination. A wonderful holiday «ABC FUN Festival» was full of English songs and games. The performance revealed that children learned not only the alphabet perfectly, but also many new words and songs. Our class seniors also took part in the festival as presenters.

A recitation contest was held for the 2nd grade students, where the little English language experts demonstrated their oratorical abilities. They really enjoyed memorizing and reciting poems. The performances of the students were bright and expressive. The most artistic readers were awarded diplomas.

An exciting quest was organized for the 3rd grade students, where the kids performed challenging and interesting tasks. Each team had its own route, through which they showed their knowledge in reading by transcription, describing pictures, how to make a letter and greeting, what symbols are used in the UK and much more. Our participants demonstrated good preparation in all aspects of the language.

The Fourth graders participated in a game called Jeopardy. They remembered many facts about the United Kingdom: from geographical and political names to culture and traditions, as well as grammatical rules. There was also an exhibition of handicrafts with the topic.

The Fifth graders competed in the «Spelling bee» contest, in which participants had to spell a word, reproducing its written, dictionary form. The winners were awarded diplomas.

A fun «Groundhog Day» event was organized for the 6th grade students. It is a traditional public holiday in Canada and the United States, celebrated annually on February 2. It is believed that on this day you should watch a groundhog crawling out of its burrow, and by its behavior you can judge the of the arrival of spring.

Our class seniors enthusiastically participated in a brainstorming session about Great Britain. They demonstrated their knowledge in a variety of areas on the topic, from geography to English celebrities.

The English Week ended with a recap and excellent grades. Overall, the festival was a success. Such events help to keep the children interested and motivated in learning English and play a big role in the educational process. The English Week was bright and interesting, it showed the high creative potential of students, bright creative individuality of some of the projects. The students showed a good level of English and the ability to use the foreign language to solve the tasks in real life situations.

***Regina Abdieva,***
***a teacher of English***

Traditions

# English Wednesday



English Wednesday is one of the most interesting traditions at Adymnar. The day begins with English radio, where our students present the theme of the day. During breaks, teachers have various quizzes, games, contests and allow the students to sing karaoke songs. Students also love to dance and sing songs, especially if they are doing it with their teachers! In this way, Adymnar students develop and improve their language skills and creativity. Through this they learn to use the language in a real English-speaking environment.

***Zulfiya Ashrapova,***
***a teacher of English***

**Наша жизнь**

# ПАРЛАМЕНТСКИЙ УРОК

**В феврале в конференц-зале «Адымнар-Нижнекамск» состоялся «Парламентский урок» с приглашением заместителя мэра Нижнекамска, депутата Городского совета Марины Камелиной.**

В ходе диалога ребята узнали о том, что такое законодательные органы власти, парламент, кто такие депутаты и каким образом осуществляется взаимодействие между жителями Нижнекамска и администрацией города. У учеников была уникальная возможность задать Марине Валерьевне свои вопросы и получить обратную связь. Например, ребята узнали, что недалеко от школы появится ледовый дворец. Марина Валерьевна отметила, что в городе и районе будет много интересных преобразований. Она пожелала ребятам хорошей учебы, быть активными и отметила, что именно ребята являются будущим города, республики и страны.

***Лилия Булатова,***
***учитель истории и обществознания***



# Миссиябез кыйммәтләребездә чагыла

**Беренче эш елында «Адымнар»да уку һәм тәрбия процессына кыйммәтләргә нигезләнгән укыту алымнары кертелә башлады.**



Миссиябезгә таянып, уку елы дәвамында укытучыларыбыз берничә мөһим кыйммәтләр өстендә эшне алып бардылар: тәртип, хөрмәт, әхлак һәм бердәмлек. Атна саен укучылар белән төрле темага багышланган очрашулар оештырылды. Әлеге очрашуларда кыйммәтләребезнең кирәклелеге турында әңгәмәләр үткәрелде.




Әлеге эш кысаларында төрле файдалы акцияләр барлыкка килде: «Айның иң яхшы сыйныфы» бәйгесе, яхшы эшләр челленджы, рәсемнәр һәм «Тәртипле укучы», «Иң яхшы дус» темаларына багышланган иншалар бәйгесе үткәрелде. Укучыларыбыз мәктәбебезнең кануннарын үзләштерделәр, һәркемгә хөрмәт күзлегеннән карарга өйрәнделәр, бергәләшеп яхшылык кылдылар һәм проектлар ясадылар.



Кыйммәтләребез өстендә эшебезне киләсе уку елында да дәвам итәчәкбез! Димәк, безне алда әле бик күп ачышлар көтә!

***Гөлназ Сәдриева, уку-укыту эшләре буенча***
***директор урынбасары***

# «КНИГИ И ЧАЙ»:
## ЧИТАЕМ ЗА ЧАШКОЙ ЧАЯ



**В школе регулярно проводятся заседания книжного клуба «Книги и чай».**

На последнем заседании клуба обсуждали книгу «Поллианна» Элинор Портер. Дети активно высказывали своё мнение. Им понравилось жизненное кредо главной героини – искать во всех событиях хорошие стороны. Ребята увлеченно находили положительное в разных ситуациях и решили, что дело Поллианны ими будет продолжено.

Книжный клуб – один из способов увлечь детей чтением. Кстати, название клубу придумали сами участники, потому что чтение интересной книги особенно приятно с чашечкой чая.

***Марина Халиуллина,***
***учитель русского языка и литературы***




*Башлангыч сыйныфлар укытучысы Эльвира Уракаева «Шахмат педагогы - 2023» бәйгесендә 3 нче урынны яулады. Горурланабыз!*

Редактор – К.С. Пушкарева. Корректор – М.В. Халиуллина.
Помощь в переводе и литературная правка на татарском языке – Э.А. Унверен.
Консультанты – А.А. Исмагилова, Г.И. Садриева, М.Р. Набиева, М.М. Гимранова.
Редакция газеты благодарит за помощь всех педагогов и детей, принявших участие в выпуске газеты. В газете размещены фото, сделанные педагогами и сотрудниками школы, а также взятые из открытых источников.

В газете размещены фото, сделанные педагогами и сотрудниками школы, а также взятые из открытых источников.
МБОУ «Адымнар-Нижнекамск», пр. Строителей, 66А. 423570, РТ, г. Нижнекамск
Телефон: 8 (8555)35-05-35.
E-Mail: adymnar.tk@inbox.ru

Отпечатано в ООО «ИПЦ «Гузель» г. Нижнекамск, пр. Химиков, д. 18, тел.: 8 (8555) 49-80-04
Заказ № 45522/23
Тираж 100 экз.
Май, 2023 г.
Вёрстка и дизайн – И.И. Шалафаев

Мы в Telegram: adymnartubenkama
Мы в «ВКонтакте»: adymnartubenkama